СОВЕТ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

02.02.2023 п.г.т. Аксубаево № 149

2023 елда Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәткә вакантлы вазыйфаны биләп торуга конкурс турында белдерү

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы карар кабул итте

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары белән Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль органнарда муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин.

2. Әлеге карарның 1 пункты Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы сайтында интернет челтәрендә урнаштырырга http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль район башлыгы,
Совет Рәисе К.К.Гилманов